КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 21 апрель г.Казань № 381

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең норматив чыгымнарын раслау турында» 2021 ел, 20 сентябрь, 889 нчы карары белән расланган 2022 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең норматив чыгымнарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең норматив чыгымнарын раслау турында» 2021 ел, 20 сентябрь, 889 нчы карары белән расланган 2022 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең норматив чыгымнарына, аларны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (механизм карарга теркәлгән).

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 20 сентябрь, 889 нчы карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 21 апрель, 381 нче карары редакциясендә)

2022 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт эшләрен башкаруга норматив чыгымнар

| Т/с | Эш башкару исеме | Норматив чыгымнар, бер елга сум |
|---|---|---|
| 1. | Архивларны архив документлары белән комплектлау | 20 721 095 |
| 2. | Архив документларының сакланышын һәм исәбен тәэмин итү | 42 478 245 |
| 3. | Архив документларын тасвирлау, белешмә-эзләү чараларын булдыру, архив фондларының составы һәм эчтәлеге турында белешмә-мәгълүмат басма-лары әзерләү | 10 360 548 |
| 4. | Дәүләт серен, архив документларындагы закон белән саклана торган башка серләрне тәшкил итүче белешмәләрне саклау һәм аларны билгеләнгән тәртиптә таратуны оештыру | 4 144 219 |
| 5. | Архив эшчәнлеге һәм идарәне документлар белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча консультация һәм методика ярдәме | 6 216 329 |
| 6. | Архив документларының белешмә һәм эзләү чараларыннан «ерактан торып» файдалану мөмкинлеген тәэмин итү | 7 252 383 |
| 7. | Архив документлары нигезендә мәгълүмати чараларны, публикатор һәм күргәзмә проектларны гамәлгә ашыру | 10 360 548 |

_________________________